Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

4 сентябрь 2019 ел № 28

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмә, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча 2019 елның 27 августындагы 6690и номерлы комиссия бәяләмәсенә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә - капиталь төзелеш объектын, шул исәптән күпкатлы торак йортларның 1-2 катында, җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторы -№4.6- «җәмәгатьчелек туклануы», Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 8 Март урамы, 23 А йорт адресы, кадастр номеры 16:45:0103:2409 җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 13 сентябре 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң бер айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуга тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 13 сентябренә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәмммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.М. Токарев